Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Өркеш авыл җирлеге Советы

# КАРАР

20.11. 2020 ел № 9

«Җир салымы турында» Өркеш авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 ноябрендәге 27 номерлы карарының 4 пункты үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Өркеш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» Өркеш авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 ноябрендәге 27 номерлы карарының 4 пункты (Өркеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 ноябрендәге 27 номерлы, 2015 елның 29 мае 21 номерлы, 2015 елның 24 ноябрендәге 11 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 13 номерлы, 2018 елның 31 октябрендәге 21 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 27 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 28 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 20 номерлы, 2020 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Өркеш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер айдан соң үз көченә керә.

Өркеш авыл җирлеге
башлыгы: А.Ш.Әгъләмова

СОВЕТ УРКУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1021607752870
ИНН 1623001822